ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 449-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 449-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2076-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Ш.Ш. Яһудин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27(I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) түбәндәге эчтәлекле $3^1 – 3^3$ пунктлар өстәргә:

«$3^1$) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче (үткән) гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль Законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәттә (хезмәттә) булучы (булган) гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) алар тарафыннан Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору бурычларын үтәү шарты белән, күрсәтелгән территорияләрдә Россия Федерациясе хокук саклау органнары хезмәткәрләре (эшләүчеләре), күрсәтелгән территорияләрдә хезмәт функцияләре һәм башка шундый ук функцияләр башкаручы гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзаллары;

$3^2$) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә

йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) алар тарафыннан Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору бурычларын үтәү шарты белән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә булышлык итүче оешма белән контракт төзегән гражданнар, аларның күрсәтелгән теорриторияләрдә махсус хәрби операциядә катнашуы шарты белән, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзаллары;

$3^3$) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә 2014 елның 11 маеннан башлап Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы Халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында хәрби гамәлләрдә катнашкан затлар, шулай ук күрәтелгән затларның гаилә әгъзалары;»;

б) $8^3 – 8^5$ пунктлар үз көчен югалткан дип таныга;

2) 2 өлештә:

а) $10^2$ пунктта «ятим балаларның» сүзләрен «инвалид балаларның, ятим балаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 17 – 21 пунктлар өстәргә:

«17) «Хәрби хезмәткәрләрнең акчалата тәэминаты һәм аларга аерым түләүләр бирү турында» 2011 елның 7 ноябрендәге Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәрләрне акчалата тәэмин итү һәм аларга аерым түләүләр бирүне тәэмин итү;

18) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^1$ һәм $3^2$ пунктларында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

19) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^3$ пунктында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

20) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^1$ һәм $3^2$ пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан гражданны хәбәрсез югалган дип тану;

21) әлеге статьяның 1 өлешендәге $3^1$ һәм $3^2$ пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан гражданны үлгән дип игълан итү.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең $3^1$ һәм $3^2$ пунктлары, 2 өлешенең 17, 18, 20

һәм 21 пунктлары нигезләмәләренең гамәли көче 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясын «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законның 20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 13 июнендәге 225-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июнендәге 275-ФЗ номерлы федераль законнар (алга таба тиешенчә – 225-ФЗ номерлы Федераль закон, 275-ФЗ номерлы Федераль закон) белән кертелгән үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

275-ФЗ номерлы Федераль закон белән түләүсез юридик ярдәм алу хокукы бирелгән затларның өстәмә категорияләре билгеләнде, төгәлрәк түбәндәгеләр:

– Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче (үткән) гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль Законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәттә (хезмәттә) булучы (булган) гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) алар тарафыннан Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору бурычларын үтәү шарты белән, күрсәтелгән территорияләрдә Россия Федерациясе хокук саклау органнары хезмәткәрләре (эшләүчеләре), күрсәтелгән территорияләрдә хезмәт функцияләре һәм башка шундый ук функцияләр башкаручы гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары;

– Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) алар тарафыннан Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору бурычларын үтәү шарты белән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә булышлык

итүче оешма белән контракт төзегән гражданнар, аларның күрсәтелгән теорриторияләрдә махсус хәрби операциядә катнашуы шарты белән, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзаллары;

– Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә 2014 елның 11 маеннан башлап Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы Халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында хәрби гамәлләрдә катнашкан затлар, шулай ук күрсәтелгән затларның гаилә әгъзалары.

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) шулай ук түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия затлар исемлегенә түбәндәгеләрне ала:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар – Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу чорында,

ихтыярый формированиедә катнашу турында (Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында) контракт төзегән гражданнар, әгәр алар Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендәге махсус хәрби операциядә катнашса, – ихтыярый формированиедә катнашу турында (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында) контракт гамәлдә булу чорында,

югарыда күрсәтелгән гражданнарның гаилә әгъзалары.

Шуның белән берлектә 225-ФЗ номерлы Федераль закон формулировкасында затлар исемлеге киңрәк, шуңа бәйле рәвештә республика законының 12 статьясындагы 1 өлешенә федераль нормадагы кебек $3^1 – 3^2$ пунктлар өстәлә, ә $8^1 – 8^2$ пунктлар үз көчен югалткан дип танылa.

225-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендәге 20 статьяның 2 өлеше нигезендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы дәүләт юридик бюролары һәм адвокатлар 20 статьяның 1 өлешендәге $3^1$ – $3^2$ пунктларында күрсәтелгән гражданнарга компенсацияләр түләү һәм социаль ташламалар билгеләү мәсьәләләре буенча консультацияләр бирә, аларның гаилә әгъзаларына затларны хәбәрсез югалган дип тану яисә үлгән дип игълан итү мәсьәләләре буенча ярдәм күрсәтеләчәк. Федераль нормадагы үлеге үзгәреш шулай ук Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 2 өлешендә дә чагылдырырга кирәк.

Моннан тыш, 275-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законның 20 статьясындагы 2 өлешенең $10^2$ пункты төгәлләштерелә, аның нигезендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы дәүләт юридик бюролары һәм адвокатлар телдән һәм язма рәвешләрдә хокукый консультацияләр бирә һәм инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга бәйле очракта гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзи. Татарстан

Республикасы Законының шундый ук нормасы (12 статьяның 2 өлешендәге 2 пункты) закон проекты белән 275-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты белән туры китерелә.

Закон проекты 2 статьядан тора.

Закон проектының 1 статьясы үз эченә Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына күрсәтелгән үзгәрешләрне ала, 2 статьясы закон проектының үз көченә керү тәртибен (рәсми басылып чыккан көненнән) җайга сала. Шул ук вакытта 225-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең $3^1$ һәм $3^2$ пунктлары, 2 өлешенең 17, 18, 20 һәм 21 пунктлары нигезләмәләренең гамәли көче 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртергә яисә кабул ителергә тиешле республика законнары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.